

Атюрьево районы Усть - Рахмановка авылында туган Ватанны саклаучы, СВО катнашучы Наиль Рамиль улы Чудинга мемориаль такта ачу тантанасы vтте.
Яшь армиячеләрнен янгыравыклы тавышына һәм олкәннәрнен рухландырылган чыгышларына кvпсанлы кунаклар һәм район халкы жыелды: алар арасында республиканын югары дәрәжәле кешеләре, район житәкчелеге, депутатлар һәм геройнын туганнары да бар иде. Чыгышлар тирән эчтәлекле һәм эмоциональ янгырады.

Мордовия Республикасы Сәламәтлек саклау министры Олег Валентинович Маркин геройнын туганнарына чын кvнелдән рәхмәт белдерде һәм тарихи мирасны саклау очен мондый дәрәжәдәге чараларнын моһимлеген билгеләп vтте.
Тарих укытучысы Тамара Адип кызы Чудина талантлы укучысы vсеп килvче буынга ориентир була алырлык Чын Кеше турында якты истәлекләрен янартып сойләде. Ә геройнын әнисе Раиса Васильевна киләчәк буыннар очен символ булып калачак улы очен мәхәббәт һәм горурлык сvзләре белән уртаклашты.
Һәйкәл янында «Юнармия» оешмасыннан мәктәп укучылары басып торуы символик мәгънәгә ия: буыннар дәвамчылыгын һәм яна россиялеләрнен югары әхлакый кыйммәтләрне сакларга әзерлеген гәvдәләндерде.
Моннан сон һәр vтеп баручы, Ватаныбызнын намусы һәм бәй-сезлеге очен гомерен биргән чын гражданиннын тормыш юлын искә алып, тыйнак плитә янында туктала алачак. Тарих Ватанга намуслы һәм кыю хезмәт итvчеләрнен исемнәрен саклап калган. Бvгенге буын егетләр дә, кызлар да, vткәндәге кvркәм vрнәкләргә ияреп, vз жирләрен яратырга һәм геройлар мирасын хормәт итәргә ойрәнсеннәр.
Ирекле һәм кочле Россиянен киләчәген саклап, ин кадерлесен - vз гомерләрен биргәннәрнен изге истәлеге киләчәк буыннар йорәгендә мәнге яшәсен.

**Саида БАЙБЕКОВА**